**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ БОЛЬШЕКУРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

**15 октябрь 2021 г.** **№57**

Татарстан Республикасы Яшел Узән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яшел Узән муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында " 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Техник хаталарны бетерү максатларында, Россия Федерациясе Салым кодексына, Татарстан Республикасы Яшел Узән муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яшел Узән муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 17.09.2001 № 55 карары гамәлдән чыгарырга.

2. Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яшел Узән муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында " 2019 елның 1 ноябрендәге 211 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.1. 1.8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

1.8) 0,001% «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтле махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Карауҗа авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Яшел Узән муниципаль районы, Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (авыл мәдәният йорты), Олы Күлбаш авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты).

**Олы Карауҗа авыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары,**
**Совет рәисе:** **И.С.Камалиев**